**Татарстан Республикасы**
**Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең**
**Балды-Кенә авылы гражданнар җыены**

# КАРАРЫ

**2021 елның 26 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Балды-Кенә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 26 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Балды-Кенә авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Балды-Кенә авылы, Гагарин урамында Бөек Ватан сугышында катнашучыларга стела урнаштыру һәм карап тоту; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Балды-Кенә авыл Гагарин урамындагы коены коймалау; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек гамәлгә ашыру;
- Балды-Кенә авылы зиратын коймалау һәм карап тоту; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек гамәлгә ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 112 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 58.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен җыенда катнашкан 58 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Балды-Кенә авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Балды-Кенә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Балды-Кенә авылы, Гагарин урамында Бөек Ватан сугышында катнашучыларга стела урнаштыру һәм карап тоту; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Балды-Кенә авылы Гагарин урамындагы коены коймалау; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек гамәлгә ашыру;

- Балды-Кенә авылы зиратын коймалау һәм карап тоту; проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек гамәлгә ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Нырья авыл җирлеге башлыгы В.В. Васильев